ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

03 октябрь 2024ел

**КАРАР**

№ 6472

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16, 48 статьялары, «Федераль мәгълүмати адреслы система турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2015 елның 5 ноябрендәге 171н номерлы боерыгы белән расланган Адрес реквизитлары сыйфатында файдаланыла торган биналарның (корылмаларның), бүлмәләрнең типлары, адреслау объектларының элементлары, урам-юл челтәре элементлары, планлаштыру структурасы элементлары исемлеге һәм Адрес барлыкка китерә торган элементларның исемен кыскарту кагыйдәләре, шәһәр Уставының 41 статьясындагы 4 бүлекнең 4.1 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына

исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәрне карап тикшерү буенча комиссия составын 2 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 3 октябрендәге
6472 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге
урам-юл челтәре элементларына исемнәр,
планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый
исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында нигезләмә (алга таба – нигезләмә) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибен билгели.

2. Нигезләмә федераль, региональ яки муниципальара әһәмияткә ия автомобиль юлларына карата кулланылмый.

3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларының типлары: аллея, бульвар, магистраль, тыкрык (переулок), мәйдан, тыкрык (проезд), проспект, тар тыкрык (проулок), урау юл (разъезд), авышлык (спуск), тракт, ябык тыкрык (тупик), урам, шоссе.

4. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге планлаштыру структурасы элементларының типлары: вал, зона (массив), квартал, чыганак (месторождение), микрорайон, яр буе, утрау, парк, порт, район, бакча, сквер, территория, гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе, коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте территориясе, торак милекчеләре ширкәте территориясе, коммерцияле булмаган яшелчәчелек ширкәте территориясе, кулланучылар кооперативы территориясе, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте территориясе.

5. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларының, планлаштыру структурасы элементларының исемнәрендә Яр Чаллы шәһәренең тарихи-мәдәни үсеше турында мәгълүмат булырга, Яр Чаллы шәһәрендәге халык яшәешенең географик, милли, көнкүреш, табигый үзенчәлекләрен чагылдырырга тиеш.

6. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементлары, планлаштыру структурасы элементлары дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренең, үз эшчәнлекләре белән киң танылган фән, мәдәният, сәнгать һәм башка иҗтимагый өлкәләр вәкилләренең (алга таба – күренекле шәхесләр) исемнәре белән аталырга мөмкин, шулай ук Яр Чаллы шәһәре һәм ил тарихында гомуми әһәмияткә ия вакыйгалар (алга таба – тарихи вакыйгалар) хөрмәтенә, һөнәри яки шәхси казанышлары шәһәр халкы рәхмәтенә лаек булган гражданнар төркемнәренең (алга таба – гражданнар төркемнәре) хөрмәтенә аталырга мөмкин.

Тарихи вакыйгаларга Яр Чаллы шәһәрендә һәм илдә гамәлгә ашырылган зур тарихи вакыйгалар һәм истәлекле фактлар, фән һәм техника өлкәсендәге ачышлар, дөнья һәм Ватан мәдәнияте һәм сәнгатендәге күренекле казанышлар керә.

7. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларының исемнәре, планлаштыру структурасы элементларының исемнәре, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләренең 4 бүлегендә бәян ителгән нормаларны исәпкә алып, хәзерге рус әдәби теле нормаларын (исемнәр татар телендә бирелгәндә – татар әдәби теле нормаларын) үтәп бирелә һәм тәрҗемә ителергә тиеш түгел.

8. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, үзгәртү, гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәр Яр Чаллы шәһәре дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән юридик затлар, шулай ук 18 яшькә җиткән, сайлау хокукына ия булган һәм яшәү урыны буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән гражданнарның кимендә 20 кешедән торган инициатив төркемнәре (алга таба – исемнәрнең инициаторлары) тарафыннан кертелергә мөмкин.

9. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турындагы карарлар, үз эшчәнлеген Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәрне карап тикшерү буенча комиссия турында нигезләмә (нигезләмәгә 1 нче кушымта) һәм әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра торган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына

исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәрне карап тикшерү буенча комиссия карарын исәпкә алып, Башкарма комитет тарафыннан кабул ителә.

10. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турындагы мәгълүматлар, дәүләт адреслар реестрын алып бару тәртибе нигезендә, Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе тарафыннан дәүләт адреслар реестрында урнаштырылырга тиеш.

## 2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү тәртибе

11. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү – аларны аеру һәм танып белү өчен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр билгеләү (алга таба – исемнәр бирү). Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәренең, планлаштыру структурасының бер типтагы берничә элементына бер үк исемне бирү рөхсәт ителми.

12. Исемнәр бирү Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларының, планлаштыру структурасы элементларының яңаларын булдырган очракта яки элек исем бирелмәгәннәренә исемнәр биргән очракта башкарыла.

Күренекле шәхес, гражданнар төркеме яки тарихи вакыйга истәлеген мәңгеләштерү максатларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, исеме мәңгеләштерелергә тиешле зат вафат булганнан соң кимендә биш ел узгач яки аның истәлегенә исем бирелә торган вакыйгадан соң биш ел узгач гамәлгә ашырыла.

13. Исем бирү турындагы тәкъдим язма рәвештә исем инициаторы тарафыннан Башкарма комитетка җибәрелә һәм анда түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) исем инициаторлары турында мәгълүматлар:

- гражданнарның инициатив төркеме өчен – тәкъдим бирү һәм җавап алу өчен гражданнарның инициатив төркеме тарафыннан вәкаләт бирелгән физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме

(булган очракта), туу датасы, яшәү урыны буенча теркәлү адресы, элемтә өчен телефон номеры (булган очракта), аның имзасы, имза кую датасы.

- юридик зат өчен – исеме, төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең индивидуаль номеры, урнашкан (теркәлгән) урыны, почта адресы, юридик зат җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы һәм имзасы, имзалау датасы;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының яки планлаштыру структурасы элементының тибы;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының яки планлаштыру структурасы элементының тәкъдим ителә торган исеме һәм аны бирү кирәклеген нигезләү;

4) күренекле шәхес, гражданнар төркеме яки тарихи вакыйга истәлеген мәңгеләштерү өчен – күренекле шәхеснең, гражданнар төркеменең гомуми танылган уңышлары һәм казанышлары турында мәгълүматны яки тарихи вакыйга турында мәгълүматны үз эченә алган күренекле шәхес, гражданнар төркеме яки тарихи вакыйга турында кыска тарихи белешмә;

5) исем бирү турында тәкъдимне карап тикшерү нәтиҗәләре турында җавап алу ысулы:

- тәкъдимдә күрсәтелгән почта адресы буенча почта аша җибәрү юлы белән язма рәвештә;

- тәкъдимдә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ формасында.

14. Исем бирү турындагы тәкъдимгә түбәндәге документлар теркәлә:

1) нигезләмәгә 2 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча гражданнарның имзалары белән имзалар кәгазе (тәкъдим гражданнарның инициатив төркеме тарафыннан бирелгән очракта);

2) урам-юл челтәре элементының яки планлаштыру структурасы элементының урнашу план-схемасы (ирекле рәвештә);

3) күренекле шәхес, гражданнар төркеме яки вакыйга хөрмәтенә урам-юл челтәре элементына исем яки планлаштыру структурасы элементына исем бирү турында тәкъдим белән мөрәҗәгать иткән очракта:

- күренекле шәхеснең үлү турында таныклык күчермәсе (күренекле шәхес вафат булган очракта);

- күренекле шәхеснең, гражданнар төркеменең казанышларын яки тарихи вакыйганың дөреслеген раслый торган архив документларының күчермәләре;

4) нигезләмәгә 3 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча гражданнарның персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы (тәкъдим гражданнарның инициатив төркеме тарафыннан бирелгән очракта).

15. Исем бирү турында тәкъдим һәм теркәлгән материаллар кергән көнне Башкарма комитет теркәүне гамәлгә ашыра һәм өч эш көне эчендә, күрсәтелгән тәкъдимне һәм материалларны карап тикшерү өчен комиссиягә җибәрә.

16. Тәкъдим нигезләмәнең 13 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән яки нигезләмәнең 14 пунктында каралган документлар булмаган очракта комиссия, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, аларны теркәгән көннән башлап өч көн эчендә, исем бирү турындагы тәкъдимне аңа теркәлгән документлар белән бергә исем инициаторына кире кайтара.

17. Исем бирү турындагы тәкъдимне кире кайтару өчен нигезләр булмаган очракта, аны теркәгән көннән башлап 30 көннән артмаган срокта комиссия исем бирү турындагы тәкъдимне карап тикшерә.

18. Исем бирү турындагы тәкъдимне карап тикшергәндә, комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

1) исем бирү мөмкинлеге турында дәлилләнгән бәяләмәләр бирү өчен, исем бирү турындагы тәкъдимнең һәм аңа теркәлгән документларның күчермәләрен Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының территориаль һәм тармак (функциональ) органнарына җибәрергә.

Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының территориаль һәм тармак (функциональ) органнары Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының территориаль, тармак (функциональ) органнары җитәкчеләре тарафыннан имзаланган нигезле бәяләмәләрне бирә һәм аларны, нигезләмәнең әлеге пунктында күрсәтелгән документлар кергән көннән соң 15 көн эчендә, комиссиягә җибәрә;

2) исем бирү турындагы тәкъдимне карап тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый оешмаларыннан, фәнни-тикшеренү институтларыннан, учреждениеләреннән һәм оешмаларыннан законда билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

3) үз утырышларына исем бирү мәсьәләсе буенча Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары җитәкчеләрен, исемнәр инициаторларын, иҗтимагый оешмалар вәкилләрен, фәнни-тикшеренү институтлары, учреждениеләр һәм оешмалар хезмәткәрләрен, башка кызыксынган затларны чакыру һәм тыңлау.

19. Комиссия исем бирү турындагы тәкъдимне карап тикшергәндә:

1) комиссиягә мөрәҗәгать иткән затларның яки органнарның нигезләмәнең 8 пунктында санап үтелгән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә вәкаләтле затларга һәм органнарга каравын билгели;

2) исем бирү турында тәкъдим кергән объект нигезләмәнең 3, 4 пунктларында санап үтелгән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына каравын билгели;

3) урам-юл челтәре элементы, планлаштыру структурасы элементы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен планлаштыру документларына туры килүне тикшерә;

4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементына, планлаштыру структурасы элементына исем бирелгән булуны билгели;

5) комиссиядә булган документларны, шул исәптән Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының территориаль һәм тармак (функциональ) органнарының дәлилләнгән бәяләмәләрен карап тикшерә;

6) исем инициаторы тарафыннан тапшырылган документлар, күренекле шәхеснең, гражданнар төркеменең казанышлары турында гомуми файдалану мөмкинлеге булган мәгълүматлар нигезендә күренекле шәхеснең, гражданнар төркеменең казанышларын карап тикшерә, шулай ук комиссия утырышына чакырылган затларның фикерләрен тыңлый;

7) комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә торган исем бирү турындагы тәкъдимне хуплау яки кире кагу турында карар кабул итә.

20. Исем бирү турындагы тәкъдим хупланган очракта, утырыш үткәрелгән көннән башлап өч эш көне эчендә комиссия утырышының беркетмәсе һәм исем бирүгә кагылышлы документлар, Башкарма комитетның исем бирү турындагы карар проектын әзерләү һәм алга таба Башкарма комитет Җитәкчесенең имзасын кую өчен, комиссия тарафыннан Башкарма комитетының архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрелә.

21. Исем бирү турындагы тәкъдимне кире кагу өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) комиссиягә мөрәҗәгать иткән затлар яки орган нигезләмәнең 8 пунктында санап үтелгән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә вәкаләтле затларга һәм органнарга карамый;

2) аңа карата исем бирү турында тәкъдим кергән объект нигезләмәнең 3, 4 пунктларында санап үтелгән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына карамый;

3) урам-юл челтәре элементы, планлаштыру структурасы элементы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен планлаштыру документларына туры килми;

4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементына, планлаштыру структурасы элементына исем бирелгән инде;

5) тәкъдим ителгән исем Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының, планлаштыру структурасы элементының башка бер типтагы элементына бирелгән инде;

6) урам-юл челтәре элементы, планлаштыру структурасы элементы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләреннән читтә урнашкан;

7) исем инициаторы тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүматлар бар;

8) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының исеме, планлаштыру структурасы элементының исеме Нигезләмәнең 5 пункты таләпләренә туры килми;

9) исем, Яр Чаллы шәһәре һәм ил тарихындагы вакыйга, алар хөрмәтенә исем бирергә тәкъдим ителә торган гражданнар төркеме нигезләмәнең 6 пункты таләпләренә туры килми;

10) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының исеме, планлаштыру структурасы элементының исеме Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бәян ителмәгән, экстремизмны, террорчылыкны, нацизмны, фашизмны, җәмгыятькә каршы һәм хокукка каршы гамәлләрне пропагандалый;

11) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементы исеменең, планлаштыру структурасы элементы исеменең язылышы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләренең 4 бүлеге таләпләренә туры килми;

12) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә яңа барлыкка килгән яисә исем бирелмәгән урам-юл челтәре элементы, планлаштыру структурасы элементы булмау.

22. Исем инициаторына исем бирү турындагы тәкъдимне карап тикшерү нәтиҗәләре турында җавап, тәкъдимне карап тикшерү өчен билгеләнгән срокта, тәкъдимдә күрсәтелгән ысул белән, комиссия утырышы беркетмәсеннән өземтә җибәрү юлы белән бирелә.

## 3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларының исемнәрен, планлаштыру структурасы элементларының исемнәрен үзгәртү тәртибе

23. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларының исемнәрен, планлаштыру структурасы элементларының исемнәрен үзгәртү – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларының исемнәрен, планлаштыру структурасы элементларының исемнәрен алмаштыру (алга таба – исемнәрне үзгәртү).

24. Исемнәрне үзгәртү түбәндәге очракларда башкарыла:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының, планлаштыру структурасы элементының ике һәм аннан күбрәк бер типтагы элементы бер һәм шул ук исемгә ия;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына тарихи исемнәрне кире кайтару;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының тибы, планлаштыру структурасы элементының тибы үзгәрү;

4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларын, планлаштыру структурасы элементларын берләштерү;

5) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементын, планлаштыру структурасы элементын берничә элементка бүлү;

6) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының исемен, планлаштыру структурасы элементының исемен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләренең 4 бүлегендә аларның язылышы буенча билгеләнгән таләпләргә туры китерү.

Исемнәрнең инициаторлары тарафыннан исемне үзгәртү турында тәкъдимнәр кертү һәм аларны комиссия тарафыннан карап тикшерү, әлеге бүлектә билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, исем бирү өчен билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

25. Исемне үзгәртү турындагы тәкъдимдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) нигезләмәнең 13 пунктындагы 4 пунктчасында каралган мәгълүматлардан тыш, нигезләмәнең 13 пунктында каралган мәгълүматлар;

2) исемен үзгәртергә тәкъдим ителә торган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының, планлаштыру структурасы элементының гамәлдәге исеме;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының гамәлдәге исемен, планлаштыру структурасы элементының гамәлдәге исемен үзгәртү сәбәбе.

26. Исемне үзгәртү турындагы тәкъдимгә, нигезләмәнең 14 пунктының 3 пунктчасында каралган документлардан тыш, нигезләмәнең 14 пунктында каралган документлар теркәлә.

27. Исемне үзгәртү турындагы тәкъдимне кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) комиссиягә мөрәҗәгать иткән затлар яки орган нигезләмәнең 8 пунктында санап үтелгән исемнәрне үзгәртү турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә вәкаләтле затларга һәм органнарга карамый;

2) аңа карата исемне үзгәртү турында тәкъдим кергән объект нигезләмәнең 3, 4 пунктларында санап үтелгән Яр Чаллы шәһәре муниципаль

берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына карамый;

3) урам-юл челтәре элементы, планлаштыру структурасы элементы Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен планлаштыру документларына туры килми;

4) тәкъдим ителгән исем Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәренең башка бер типтагы элементына, планлаштыру структурасының башка бер типтагы элементына бирелгән инде;

5) урам-юл челтәре элементы, планлаштыру структурасы элементы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләреннән читтә урнашкан;

6) исем инициаторы тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүматлар бар;

7) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының исеме, планлаштыру структурасы элементының исеме нигезләмәнең 5 пункты таләпләренә туры килми;

8) тәкъдим ителгән исемне үзгәртү нигезләмәнең 24 пунктында күрсәтелгән очракларга карамый;

9) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының исеме, планлаштыру структурасы элементының исеме Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бәян ителмәгән, экстремизмны, террорчылыкны, нацизмны, фашизмны, җәмгыятькә каршы һәм хокукка каршы гамәлләрне пропагандалый;

10) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементы исеменең, планлаштыру структурасы элементының исеменең язылышы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләренең 4 бүлеге таләпләренә туры килми.

28. Исемне үзгәртү турындагы тәкъдимне кире кагу өчен нигезләр булмаган очракта комиссия, комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә торган исемне үзгәртү турындагы тәкъдимне хуплау турында карар кабул итә.

29. Утырыш үткәрелгән көннән башлап өч эш көне эчендә комиссия утырышының беркетмәсе һәм исемне үзгәртүгә кагылышлы документлар, Башкарма комитетның исемне үзгәртү турындагы карар проектын, кирәкле документларны әзерләү һәм алга таба Башкарма комитет Җитәкчесенең имзасын кую өчен, комиссия тарафыннан Башкарма комитетының архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрелә.

## 4. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларының исемнәрен, планлаштыру структурасы элементларының исемнәрен гамәлдән чыгару тәртибе

30. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларының исемнәрен, планлаштыру структурасы элементларының исемнәрен гамәлдән чыгару (алга таба – исемнәрне гамәлдән чыгару) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларының, планлаштыру структурасы элементларының гамәлдә булуы туктатылган очракта башкарыла.

31. Исемнәрне юкка чыгару турында исемнәрнең инициаторлары тарафыннан тәкъдимнәр кертү һәм комиссия тарафыннан карап тикшерү, әлеге бүлектә билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, исемнәр бирү өчен билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

32. Исемне гамәлдән чыгару турындагы тәкъдимдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) нигезләмәнең 13 пунктындагы 3, 4 пунктчаларында каралган мәгълүматлардан тыш, нигезләмәнең 13 пунктында каралган мәгълүматлар;

2) исемен гамәлдән чыгару тәкъдим ителә торган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының исеме, планлаштыру структурасы элементының исеме;

3) исемне гамәлдән чыгару сәбәбе.

33. Исемне юкка чыгару турындагы тәкъдимгә түбәндәге документлар теркәлә:

1) нигезләмәгә 2 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча гражданнарның имзалары белән имзалар кәгазе (тәкъдим гражданнарның инициатив төркеме тарафыннан бирелгән очракта);

2) урам-юл челтәре элементы яки планлаштыру структурасы элементы урнашкан урынның план-схемасы (ирекле рәвештә);

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементының, планлаштыру структурасы элементының гамәлдә булуын туктату фактын раслый торган документлар;

4) нигезләмәгә 3 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча гражданнарның персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы (тәкъдим гражданнарның инициатив төркеме тарафыннан бирелгән очракта).

34. Исемне гамәлдән чыгару турындагы тәкъдимне кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) комиссиягә мөрәҗәгать иткән затлар яки орган нигезләмәнең 8 пунктында санап үтелгән исемнәрне гамәлдән чыгару турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә вәкаләтле затларга һәм органнарга карамый;

2) аңа карата исемне гамәлдән чыгару турында тәкъдим кергән объект нигезләмәнең 3, 4 пунктларында санап үтелгән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына карамый;

3) урам-юл челтәре элементы, планлаштыру структурасы элементы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләреннән читтә урнашкан;

4) исем инициаторы тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүматлар бар.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетының
2024 елның 3 октябрендәге
6472 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге
урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы
элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү,
гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәрне карап тикшерү буенча
комиссия составы

1. Салахов Фәрид Шавкат улы – комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе;

2. Фәттахов Мансур Әдип улы – комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары;

3. Мөхәммәдиева Камалия Илдар кызы – комиссия секретаре, «Шәһәр төзелешен үстерү хезмәте» ҖЧҖ геодезия бүлегенең 1 нче категория инженеры;

комиссия әгъзалары:

4. Әхмәтҗанов Ленар Илдар улы – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Комсомол районы хакимияте Башлыгы;

5. Батюшов Абдулхак Мостафа улы – Шәһәр Советы депутаты, мәгариф, мәдәният, милли мәсьәләләр, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссия рәисе, «СТВ МЕДИА» ҖЧҖ генераль директоры (килешү буенча);

6. Бодрова Ирина Аркадьевна – «10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ директоры (килешү буенча);

7. Вилданов Руслан Флер улы – Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы;

8. Канеев Билял Абдрахман улы – туган якны өйрәнүче, Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (килешү буенча);

9. Капитова Юлия Александровна – «Тарихи-туган якны өйрәнү музее» МАМУ директоры;

10. Петров Альберт Николаевич – Шәһәр Советы депутаты, шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссия әгъзасы, «Камгэсэнергострой» КТИ ҖЧҖ генераль директоры, Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (килешү буенча);

11. Рзаева Гөлзада Мөхәммәтгәрәй кызы – Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (килешү буенча);

12. Сәлмәнов Ленар Ирек улы – «Шәһәр төзелешен үстерү хезмәте» ҖЧҖ генераль директоры;

13. Сафин Факил Миңнемөхәммәт улы – «Көмеш кыңгырау» газетасының баш редакторы, Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлеге рәисе, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (килешү буенча);

14. Суворов Виктор Семенович – «Яр Чаллы технология техникумы» ДАҺББУ директоры, Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (килешү буенча);

15. Рәҗәпов Артур Җәүдәт улы – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Үзәк районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы;

16. Халимов Рамил Мәрван улы – Яр Чаллы шәһәре Хакиме ярдәмчесе (килешү буенча);

17. Харисов Винер Хәмит улы – Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары;

18. Хөсәенов Уел Галим улы – Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (килешү буенча);

19. Хөснуллин Айрат Шәүкәт улы – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Автозавод районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы;

20. Шәрипов Әнвәр Мәгъдәнур улы – филология фәннәре докторы, «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» ЮҺББ ФДБМУ профессоры (килешү буенча);

21. Ямашев Сергей Павлович – «КамГэсэнергострой» АҖ төзелеш буенча директор урынбасары, Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (килешү буенча).

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәрне карап тикшерү буенча комиссия турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәрне карап тикшерү буенча комиссия турында нигезләмә (алга таба – нигезләмә) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәрне карап тикшерү буенча комиссиянең (алга таба – комиссия) бурычларын, функцияләрен, хокукларын, эшчәнлеген оештыруны билгели.

2. Комиссия Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәрне карап тикшерү максатында булдырылган даими эш итүче коллегиаль орган булып тора.

3. Комиссия кимендә 19 кешедән торырга тиеш.

Комиссия составы һәм аның составының үзгәрүе Башкарма комитет карары белән раслана.

4. Үз эшчәнлегендә комиссия Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль хокукый актларга таяна.

## 2. Комиссиянең төп функцияләре

5. Комиссиянең төп функцияләренә түбәндәгеләр керә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында

тәкъдимнәрне (алга таба – исемнәр бирү, исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәр) карап тикшерү;

2) исемнәр бирү, исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәрне хуплау яки кире кагу турында карарлар кабул итү;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән затларга (алга таба – исемнәр инициаторлары), комиссия утырышы беркетмәсеннән өземтәләр җибәрү юлы белән, исемнәр бирү, үзгәртү, гамәлдән чыгару турында тәкъдимнәргә җаваплар әзерләү һәм җибәрү.

## 3. Комиссиянең хокуклары

6. Комиссия түбәндәге хокукларга ия:

1) исем бирү мөмкинлеге турында дәлилләнгән бәяләмә бирү өчен, исемнәр бирү, үзгәртү, гамәлдән чыгару турындагы тәкъдимнәрнең һәм аларга теркәлгән документларның күчермәләрен Башкарма комитетның территориаль һәм тармак (функциональ) органнарына җибәрергә;

2) исемнәр бирү, үзгәртү, гамәлдән чыгару турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый оешмаларыннан, фәнни-тикшеренү институтларыннан, учреждениеләреннән һәм оешмаларыннан законда билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

3) кирәк булган очракта, географик объектларның, шәһәр мохите объектларының һәм шәһәр территориясенең башка состав өлешләренең тарихына, хәзерге торышына һәм үсеш перспективаларына кагылышлы мәсьәләләр буенча Башкарма комитетның структур бүлекчәләре җитәкчеләрен, Шәһәр Советы депутатларын, галимнәрне, иҗтимагый оешмалар вәкилләрен, башка кызыксынган затларны үзләренең утырышларында катнашуга чакырырга.

## 4. Комиссия эшен оештыру

7. Комиссия эшен оештыру өчен комиссия составына комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре, комиссия әгъзалары керә.

8. Комиссия рәисе түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

2) комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибе проектын формалаштыра;

3) комиссия утырышын үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгели;

4) комиссия утырышында рәислек итә;

5) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына

исемнәр бирү турында нигезләмә һәм әлеге нигезләмә нигезендә комиссиянең эшен оештыра;

6) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм гражданнар белән мөнәсәбәтләрдә комиссия исеменнән эш алып бара;

7) комиссия утырышлары беркетмәләрен имзалый.

9. Комиссия рәисе урынбасары, рәис булмаганда, комиссия рәисе вазыйфаларын башкара.

10. Комиссия секретаре:

1) исемнәр бирү, үзгәртү, гамәлдән чыгару турындагы тәкъдимнәрне кабул итүне һәм теркәүне гамәлгә ашыра;

2) исемнәр бирү, үзгәртү, гамәлдән чыгару турындагы тәкъдимнәргә җаваплар җибәрүне гамәлгә ашыра;

3) комиссия утырышын әзерләүне гамәлгә ашыра;

4) комиссия әгъзаларына комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, аның утырышының көн тәртибе турында мәгълүмат бирә, комиссия утырышы көненә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, карар кабул итү өчен кирәкле материалларны комиссия әгъзаларына җибәрә;

5) комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

6) комиссия утырышлары беркетмәләрен имзалый;

7) комиссиянең агымдагы архивын формалаштыра;

8) комиссия рәисе йөкләмәләрен үти.

11. Комиссия әгъзалары комиссия утырышында карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча һәм комиссия эшчәнлеген оештыру буенча тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

12. Комиссия утырышлары кирәк булган саен үткәрелә.

13. Комиссия утырышларын комиссия рәисе, ә ул булмаганда комиссия рәисе урынбасары алып бара.

14. Әгъзаларының яртысыннан күбесе катнашса, комиссия утырышы тулы хокуклы була.

15. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының яртысыннан күбесе аның өчен тавыш бирсә, карар кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булган очракта, комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

16. Комиссия карары, комиссия утырышында рәислек итүче һәм комиссия секретаре тарафыннан имзалана торган беркетмәдә теркәлә.

17. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

2) комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр;

3) комиссия утырышында катнашкан комиссия әгъзалары турында мәгълүматлар;

4) комиссия утырышына чакырылган башка затлар турында мәгълүматлар;

5) комиссия утырышында карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча комиссия әгъзаларыннан кергән тәкъдимнәр;

6) комиссия утырышында карап тикшерелгән мәсьәләләр буенча тавыш бирү йомгаклары;

7) карап тикшерелә торган мәсьәләләрнең һәркайсы буенча комиссия карары;

8) комиссия карары белән килешмәгән комиссия әгъзасы үзенең аерым фикерен язма рәвештә җиткерергә хокуклы, ул комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлә.

18. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документлар белән тәэмин итү Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Имзалар кәгазе

Без, түбәндә имза куючылар, исем бирү (үзгәртү, гамәлдән чыгару) буенча инициатив төркем әгъзалары булып торабыз:

Урам-юл челтәре элементының тибы (планлаштыру структурасы элементының тибы), аның исеме (исемне үзгәрткән яки гамәлдән чыгарган очракларда), аның урнашу урыны (Яр Чаллы шәһәре районы), тәкъдим ителә торган исеме (исеме бирелгән яки исеме үзгәртелгән очракта) күрсәтелә ____________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Исем бирү (үзгәртү, гамәлдән чыгару) турында тәкъдим бирүгә һәм җавап алуга безнең вәкаләтле вәкил булып тора:

________________________________________________________________________

(тәкъдим бирүгә һәм җавап алуга инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелә)

| № т/б | Ф.И.А.и. | Туган көне, ае, елы | Яшәү урыны адресы (даими теркәлү урыны) | Граждан паспортының яки паспортны алмаштыра торган документның сериясе, номеры | Телефон номеры (булган очракта) | Имза кую датасы | имза |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Имзалар кәгазен таныклыйм:
Имзалар җыюны гамәлгә ашыручы зат:

________________________________________________________________________

(үз кулы белән күрсәтелгән фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы,

________________________________________________________________________

граждан паспортының яки паспортны алмаштыра торган документның номеры һәм бирү датасы,

________________________________________________________________________

граждан паспортын яки паспортны алмаштыра торган документны биргән органның исеме яки коды, яшәү урыны адресы (даими теркәлү урыны), имза һәм аны кую датасы)

Инициатив төркемнең исем бирү (үзгәртү, гамәлдән чыгару) турында тәкъдим бирүгә һәм җавап алуга вәкаләтле вәкиле:

________________________________________________________________________

(үз кулы белән күрсәтелгән фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы,

________________________________________________________________________

граждан паспортының яки паспортны алмаштыра торган документның номеры һәм бирү датасы,

______________________________________________________________________________

граждан паспортын яки паспортны алмаштыра торган документны биргән органның исеме яки коды, яшәү урыны адресы (даими теркәлү урыны), имза һәм аны кую датасы)

______________________________________________________________________________

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү турында, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык формасы

Мин, ____________________________________________________________________,
(персональ мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

_____________________________________________________________ адресы буенча яшәүче
(персональ мәгълүматлар субъектының яшәү урыны адресы)
шәхесен раслый торган төп документ:

_______________________________________________________________________________
(персональ мәгълүматлар субъектының шәхесен раслый торган төп документның исеме һәм номеры, күрсәтелгән документны бирү датасы һәм аны биргән орган турында мәгълүматлар)

персональ мәгълүматлар субъекты булып торучы «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9-11 статьялары нигезендә «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9-11 статьялары нигезендә, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 адресы буенча урнашкан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урам-юл челтәре элементларына исемнәр, планлаштыру структурасы элементларына бирү (үзгәртү, гамәлдән чыгару) турындагы тәкъдимне карап тикшерү максатларында түбәндәге мәгълүматларны: фамилия, исем, әтиемнең исеме; туган ел, ай, дата һәм урын; теркәлү һәм яшәү адресы; телефон номерын (эш, кәрәзле, факс) эшкәртүгә, ягъни, күрсәтелгән персональ мәгълүматлар белән автоматлаштыру чараларыннан фадаланып яки мондый чаралардан файдаланмыйча башкарыла торган гамәлләрне (операцияләрне) башкаруга, шул исәптән җыюга, язуга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), өземтә алуга, файдалануга, тапшыруга (таратуга, бирүгә, файдалану мөмкинлегенә), шәхес үзенчәлекләрен бетерүгә, блокировкалагауга, бетерүгә, юкка чыгаруга ризалык бирәм.

Әлеге ризалык «____» ____________ 20___ елдан башлап гамәлдә һәм срогы чикләнмәгән, һәм минем язма гаризам буенча теләсә кайсы вакытта кире алынырга мөмкин.
Персональ мәгълүматларны саклау өлкәсендә минем хокукларым һәм бурычларым турында миңа аңлатуны раслыйм.

_________________________

__________
«_____» ___ 20__ел

(Персональ мәгълүматлар субъектның
Ф.И.А.и. (атасының исеме – булган очракта)
(имза))